Структурное подразделение Муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения
«Татарско-Ямалинская основная общеобразовательная школа»
Актанышского муниципального района РТ-
ОУ «Буляковская начальная школа»

| Обсуждено<br>Руководитель ШМО МБОУ<br>«Татарско-Ямалинская ООШ» АМР РТ<br>_____ /Варина Т.Р./<br>Проткол № 1<br>от « 21 » авг. 2018 г. | Согласовано<br>Заместитель директора по УВР<br>МБОУ «Татарско-Ямалинская ООШ» АМР РТ<br>_____ /Шаймухаметова Р.Р./<br>« 23 » август 2018 г. | Утверждаю<br>Директор МБОУ «Татарско-Ямалинская ООШ» АМР РТ<br>_____ /Файрушина Г. Г./<br>Приказ № 70-од<br>От « 28 » августа 2018 г. |
|---|---|---|

Рабочая программа по предмету **«Литературное чтение на родном языке», 3 класс**
Составитель: Нуриева Разима Абударовна,
учитель начальных классов первой квалификационной категории

Рассмотрено на заседании
педагогического совета.
Протокол № 1
от « 28 » августа 2018 г.

2018-2019 учебный год

**Предмет буенча планлаштырылган нәтиҗәләр**

| Бүлек исеме | Предмет нәтиҗәләре | | Метапредмет нәтиҗәләре | Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|---|
| | Укучы өйрәнәчәк | Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак | | |
| Халык авыз иҗаты әсәрләре. Әкиятләр. Мәсәл жанры. Мәкаль жанры | -тылсымлы, хайваннар турындагы әкиятләрне, мәсәлләрне, тормыш-көнкүреш әкиятләрен аерырга;<br>- тормыш-көнкүреш һәм тылсымлы әкиятләрнең үзенчәлегеначыкларга;<br>-әкият белән хикәяне аерырга;<br>-әсәрдә сурәтләү чараларын табарга (чагыштырулар, капма-каршылык, кабатлаулар, җанландыру). | -хайваннар турындагы әкиятләрнең кайчан килеп чыгышы турында фикерләргә;<br>- төрле халыклар әкиятләрендә йөремсәк сюжет булуын ачыкларга. | **Регулятив күнекмә:**<br>-максатка ирешүдә үҗәтлек, авырлыкны җиңүгә әзер булу, авырлыкларны чишү ысулларын эзләүгә ихтыяҗ формалаштырга;<br>-ирешеләчәк нәтиҗәне алдан күрергә;<br>-үтәлгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләргә, уңышлылыгына бәя бирергә;<br>-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылырга;<br>-укытучы белән хезмәттәшлектә итәргә;<br>**Танып -белү күнекмәсе:**<br>-эшчәнлек барышын һәм нәтиҗәләрен тикшереп һәм бәяләп барырга;<br>-охшашлык һәм аермалыкларны аерырга, чагыштырырга;<br>-проблеманы кыска һәм ачык итеп әйтергә;<br>-проблеманы чишү алымнарын хезмәттәшлектә табарга.<br>**Коммуникатив күнекмә:**<br>-укытучы, туганнар, әти-әниләр белән хезмәттәшлекне планлаштыру – катнашучыларның максатларын, вазифаларын үзара аралашу ысулларын билгеләргә; | -үз илең, халкың һәм тарихың белән горурлану хисләре формалаштырырга, һөнәрләр дөньясы белән танышырга, җәмәгать урыннарында, мәктәптә үз-үзеңне тотуның әхлакый кагыйдәләрен үзләштерергә;<br>-уку эшчәнлеге һәм аның мотивлары арасында элемтә урнаштырырга;<br>әдәби мәдәният нигезендә матурлыкны күрә белү һәм эстетик хисләр формалаштырырга.<br>белем бирү учреждениесенә унай караш, әдәби уку фәнен өйрәнүнең кирәклеген аңларга;<br>уку эшчәнлегенең уңышлылыгы (унышсызлылыгы) сәбәпләрен аңларга;<br>-аралашканда иптәшеңнең мотивларына һәм хисләренә ориентлашырга, үз-үзеңне тотышында мораль нормаларга һәм этик таләпләргә тотрыклы иярергә. |
| Әдәби жанрлар. Хикәя. Әкият.<br>Библиографик культура<br>Уку , сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру | -сүзләрне укыганда төгәл, дөрес әйтеп укырга, уку тизлеген арттыра барырга;<br>- текст белшн беренче танышканда эчтән укырга, терък сүзләрне эзләп табып, ирәкле өзек белән танышырга, өзекне сайлап укырга;<br>- укытучыны, | - мөстәкыйль рәвештә тематик , жанрлар буенча җыентыклар төзергә;<br>-уку өчен мөстәкыйль рәвештә китаплар сайлап, китап элементлары буенча эчтәлекне ачыкларга; | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | сыйныфтаәларын тыңларга, сорауларга җавап иптәшләрен кабатламаска, үз фикерләрен төгәл әйтә белергә;<br>- төрле авторның 6-8 әсәрен яки алардан өзекне яттан сөйләргә;<br>-үзе яраткан автор, аның әсәрләре турында сөйли белергә;<br>- бирелгән текстын темасын төп мәгънәсен ачыкларга, авторның үз героена мөнәсәбәтен билгеләргә;<br>- әсәр геройларына характеристика бирергә;<br>- укылган әсәрнең эчтәлеген аңларга, интонация, уку темпын сайларга паузалар белән укырга;<br>- әсәрләр буенча инсценировкалар әзерләгәндә катнашырга. | - сайлап алынган китапларны мөстәкыйль укырга;<br>- сүзлекләр белән мөстәкыйль эш итәргә;<br>- шигъри һәм проза әсәрләрен сәнгатьле укып, текстка карата үз мөнәсәбәтеңне белдерергә;<br>- дәреслектә бирелгән иллюстрацияләрне әдәби текстлар белән чагыштырып, уртак һәм аермалы якларын табарга;<br>- әдәби һәм сәнггать әсәрләре турында телдән сөйләм төзергә. | -сораулар формалаштырырга, җитмәгән мәгълүматны башкалардан сорашып белергә;<br>-эшлекле партнерлы аралашырга, төркемдә үзара ярдәм итешергә. | |

**3 нче сыйныфта әдәби укуның эчтәлеге**

| Бүлек исеме | Кыскача эчтәлек | Сәгать саны |
|---|---|---|
| **Халык авыз иҗаты әсәрләре** | **Әкиятләр.**Халык авыз иҗатының бер төре булган һәм җир йөзендәге барлык милләтләрдә дә яшәп килүче, буыннан буыннарга күчеп йөри торган хайваннар турындагы әкиятләргә карата гомуми күзаллау булдыру. Әкиятләрнең гасырлар дәвамында үсеше. Гади вакыт тасмасы: 1) бик борынгы әкиятләр, 2) борынгы, 3) бик борынгы булмаган әкияти вакыйгалар турында аңлату.<br>Бик борынгы әкиятләрдә хайваннар арасындагы мөнәсәбәтләр, аларның тышкы күренешләре төп урынны алып тора. Борынгы әкиятләрдә геройның аңы, хәйләгә осталыгына дан җырлана. Ә әкияти вакыйгалар исә үз эченә геройның изге эшләрен, аның сәләтен, киң күңеллеген күрсәтүне максат итеп куя. Йөремсәк әкиятләр турында күзаллау булдыру.<br>**Мәсәлләр.** Мәсәлләрнең ике өлештән: хикәяләү (вакыйга) һәм моральдән (нәтиҗә, тәрбияви аңлату) торуын аңлату. Мәсәлдәге хикәяләү өлешенең әкиятләрдән килеп чыгуына басым ясау. Мәсәлләрнең мораль өлешенең мәкальләр белән охшашлыгы. Мәсәл жанрының килеп чыгышы, үсеше. Бөтен дөньяга танылган мәсәлчеләр: Эзоп, Ж. Лафонтен, И. Крылов, татар мәсәлчеләре К. Насыйри, Г. Тукай, М. Гафури, Г. Шамуков, Ә. Исхак һәм башка язучылар әсәрләрен өйрәнү.<br>**Мәкальләр.** Мәкальләр – ул борынгылар сүзе, аталар сүзе, картлар сүзе, тәҗрибә һәм хикмәт җимеше, хәтердә сакланырга тиешле хәзинә, халыкның күмәк фикере, тормыш кагыйдәсе, сүзгә дәлил, тормышта киңәш. “Мәкаль” сүзе гарәп теленнән алынган, “урынлы сүз яки тиешле урында әйтелгән сүз” дигән мәгънәне аңлатуын төшендерү. Төрле халык мәкальләре. Мәкальләрне сөйләмдә, мәсәлләрдә урынлы куллану.. | 6<br><br><br><br><br><br><br><br>7<br><br><br><br><br>3 |
| **Әдәби жанрлар** | **Хикәя.** Хикәя жанры турында күзаллау формалаштыру. Хикәя геройлары аларның портреты һәм характер үзенчәлекләренең башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырмача характеристика. Герой яшәгән тирәлек, пейзаж.<br>Әкият һәм хикәя жанрының үзгәлеге турында күзаллау формалаштыру**.** Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы-тыңлауга табигый көчләрнең серен, әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының характерларында тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү.<br>**Шигърият**<br>Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөнья матурлыгын шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуын инандыру. Шагыйрьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет.<br>Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру,контраст,җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре:темп,тавыш көче,тон,сөйләм мелодикасы(тавышны күтәрү ,түбәнәйтү).<br>**Вакыт тасмасы** | 29<br><br><br><br><br><br><br>23<br><br><br><br><br><br><br>Халык авыз |

| | | |
|---|---|---|
| | Фольклор әсәрләреннән әкиятләрне вакыт тасмасында күрсәтү (бик борынгы,борынгы,әкияти вакыйгалар ). | иҗаты бүлегендә |
| **Библиографик культура** | Эчтәлек бите белән танышу, аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү, кече яштәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эшчәнлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп өч элементын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру. Төрле җыентыклар төзергә өйрәнү. | Башка бүлекләр кысаларында тормышка ашырыла |
| **Уку , сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру** | Сәнгатьле уку *( интонация, тон, темп саклап кычкырып уку)*. Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау. Уку техникасын үстерү. | Башка бүлекләр кысаларында тормышка ашырыла |

| *Укыла торган әсәрләрнең тематик блокларга бүленеше.* | | |
|---|---|---|
| 1 нче бүлек | Күзәтәбез һәм тәэсирләр белән уртаклашабыз. | 14 сәг |
| 2 нче бүлек | Чагыштырулар серенә төшенәбез | 6 сәг |
| 3 нче бүлек | Кешеләрнең хыялларын аңларга тырышабыз. | 7 сәг |
| 4нче бүлек | Ярату турында. | 9 сәг |
| 5 нче бүлек | Хикмәтле тормыш тәҗрибәсе туплыйбыз. | 7 сәг |
| 6 нчы бүлек | Көлке серләрен эзлибез. | 5 сәг |
| 7 нче бүлек | Герой ничек туа? | 9 сәг |
| 8 нче бүлек | Үткәннәр белән хәзергене чагыштырабыз | 14 сәг |

Календарь-тематик план

| № | Өйрәнелә торган бүлек, дәрес темасы | Сәгать саны | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | План. вакыт | Фактик вакыт |
| 1. | **Библиографик культура. Мәкальләр.**<br>**Күзәтәбез һәм тәэсирләр белән уртаклашабыз.** 14сәг<br>Китапның өч элементы. Китап белән танышу. Татарстан Республикасы символикасы. Төрле халык мәкальләре. | 1 | | |
| 2. | **Әдәби жанрлар. Шигърият.** Китапханәләрдән файдалана белү<br>Б.Рәхмәт. “Иң күңелле чак”. И.Грабарь “Сентябрь кары”. Музыка: “Тын бакчада”(Ә.Ерикәй сүз.,татар халык көе) Р.Вәлиева “Җәй белән бала”. Шигырьдәге чагыштыру. | 1 | | |
| 3. | **Әдәби жанрлар. Шигърият.** Геройның эчке дөньясын аның әйләнә-тирә дөньяны танып белүе аша күрсәтү.<br>М.Галиев ”Җиләктән кайтканда”. Г.Эйдинов. “Мастерской тәрәзәсе”. Музыка:”Таң атканда”(С.Хәким сүз., татар халык көе) | 1 | | |
| 4. | **Әдәби жанрлар. Шигърият.** Шигырьләрдә чагыштыруны таба белү.<br>Б.Рәхимова. “Шук болытлар, батыр җил, якты кояш”. Р.Корбан “Көз нигә моңая?” Р.Вәлиева “Яңгыр,яу!” җыры. | 1 | | |
| 5. | **Әдәби жанрлар. Шигърият.**Шигырьләрдә сынландыруны таба белү.<br>Л.Лерон. “Яңгырның ял көне”, Р.Вәлиева “Китмә әле, бераз тор”,М.Әлимбаев.”Салават күпере”, М.Җәлил”Яңгыр” шигырьләре. | 1 | | |
| 6. | **Әдәби жанрлар. Шигърият.** Шигырьләр аша әйләнә-тирә дөньяны табу.<br>Р.Мингалим. “Август каеннары”. З.Туфайлова. “Яфрак ява”. Ш.Маннур”Көзге урманда”. | 1 | | |
| 7. | **Әдәби жанрлар. Хикәя.**Үзеңнең күзәтүләреңбуенча хикәяләү характерындагы зур булмаган текстлар төзү.Ф.Хөсни”Сайланма әсәрләр”, К.Тәхау. “Табигать мизгелләре” китабы, “Көзге урман. | 1 | | |
| 8. | **Әдәби жанрлар. Хикәя.** Әдәби әсәрләрнең башка сәнгать әсәрләре белән бәйләнеше. Интонация, темп, тон төшенчәләре. М.Мазунов”Карап торам”.Г.Хәсәнов”Кыр казы”. “Казлар” картинасы. | 1 | | |
| 9. | **Әдәби жанрлар. Хикәя.** Хикәя геройларының характеры сөйләм һәм вакыйгалар аша чагылышы. Г.Бәширов “Ана каз белән ата каз һәм аларның унике бәбкәсе” | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Н.Гыйматдинова.Казлар. | | | |
| 10. | **Әдәби жанрлар. Хикәя.** Хикәядә авторның үз геройларына мөнәсәбәте. Г.Остер. “Серне ачты”. В.Хәйруллина “Тәрбияче попугай”. Геройларның портреты , характеры. | 1 | | |
| 11. | **Әдәби жанрлар. Хикәя.** Кеше һәм табигать бергәлеге.<br>Н.Сладков “Күзалдавычлар”.Р.Әхмәт. “Сыкы”, “Февраль зәңгәрлеге”, “Кышкы зәңгәрлек” картиналары | 1 | | |
| 12. | **Әдәби жанрлар. Хикәя.**Геройның эчке дөньясын аның әйләнә-тирә дөньяны танып белүе аша күрсәтү<br>Н.Сладков .”Кем остарак?”Р.Корбан “Мәктәпкә озату бәйрәме”. | 1 | | |
| 13. | **Әдәби жанрлар. Шигърият.** Шагыйрьләр иҗат иткән дөнья белән чынбарлык арасындагы охшаш һәм аермалы якларны билгеләү. Г.Паушкин “Кыш”, Г.Рәхим “Безнең тауда” -матурлыкны бергәләп күреп аңлашабыз | 1 | | |
| 14. | **Әдәби жанрлар. Шигърият.** Шигырьдән әдәби сурәтләү чараларын (чагыштыру, җанландыру) эзләп табу. Хикәя геройларының портретлары, характеры сөйләм һәм вакыйгалар аша чагылышы.<br>Н.Әхмәдиев. “Чишмәгә суга барам”, Н.Гыйматдинова. “Сарбай”. | 1 | | |
| 15. | **Халык авыз иҗаты. Әкият.** Чагыштырулар серенә төшенәбез. 6 сәг<br>Кешелек дөньясы һәм тылсымлы дөнья арасындагы бәйләнеш. Әфган халык әкияте:”Иң яхшы дару”.Уйгур халык әкияте:”Тылсымлы китмән”. | 1 | | |
| 16. | **Халык авыз иҗаты. Әкият.** Хайваннар турында әкиятләр.<br>“Көрән төстәге пингвин баласы” Инглиз халык әкияте. Э.Шәрифуллина”Әкият кайда?” | 1 | | |
| 17. | **Халык авыз иҗаты. Әкият.** Хайваннар турында әкиятләр.<br>Охшашлык. Монгол халык әкияте:”Әтәч таңда нигә кычкыра”.Алман халык әкияте:”Сандугач белән Аю” | 1 | | |
| 18. | **Халык авыз иҗаты. Әкият.** Әкиятләрне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү. Манси халык әкияте.”Куянның колагы нигә озын?”<br>Эстон халык әкияте.”Куянның ирене ни гә ярык?” | 1 | | |
| 19. | **Халык авыз иҗаты. Әкият.** Әкиятләрне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү.“Кабардин халык әкияте: “Җәнлекләр патшасы”.Латыш халык әкияте:”Шайтанга ничә яшь?” | 1 | | |
| 20. | **Халык авыз иҗаты. Әкият.**<br>Йөремсәк әкиятләр турында төшенчә. Венгр халык әкияте: ”Комсызлык бәласы”.Африка негрлары әкияте:”Сырны ничек бүлгәннәр?”Литва халык әкияте: ”Итәгатьле мәче” | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 21. | **Әдәби әсәрләр. Шигърият. Хикәя.**<br>**Кешеләрнең хыялларын аңларга тырышабыз.7сәг.**<br>Аңлап һәм сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү. Л.Лерон"Хыял", "Хыялый Акбай". Йолдыз "Антенналы бәрәңге", Ш.Маннур "Көзге урманда". Шигырьдәге сынландыру. | 1 | | |
| 22. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.** Хикәягә карата үз фикереңне әйтә белү. Үз күзәтүләреңнән, уй-кичерешләреңнән чыгып хикәяләү.<br>Геройларга чагыштырмача характеристика. Л.Лерон."Мәче малае Шукбай"1,2 бүлекләр. | 1 | | |
| 23. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.** Әсәр геройларына карата үз фикереңне белдерү. Л.Лерон "Шукбай балык тота","Хат". | 1 | | |
| 24. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.** Әсәр геройларына карата үз фикереңне белдерү. Р.Фәйзуллин. "Тугайда". А.Әхмәтгалиев "Болытта җиләк үсә". | 1 | | |
| 25. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.** Укылган әсәрне анализлый белү.<br>А.Гыйләҗев "Суык", А. Алланазаров "Кыш кайчан була". Шигырьдәге эпитет. | 1 | | |
| 26. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.** Рифманы сиземли, таба белергә күнектерүА.Алланазаров."Дустымны эзлим".В.Хәйруллина"Кем булам?". Шигырьдәге эпитет. | 1 | | |
| 27. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя. Мәкальләр.**Хикәя герое. Характер һәм тойгылар үзенчәлеге. Р.Гыйззәтуллин."Батырлык", Г.Рәхим "Иске самовар торбасы". | 1 | | |
| 28. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.**<br>**Ярату турында.9сәг**<br>Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү. Р.Вәлиев. "Барысын да яратам", Ш.Маннур"Яратам", Р.Вәлиев"Чыпчык". | 1 | | |
| 29. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.** Геройларның характерына чагыштырма анализ.<br>А.Гыймадиев."Шәмси маҗаралары". Вакыт тасмасы. | 1 | | |
| 30. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.** Әсәрдән әдәби сурәтләү чараларын (чагыштыру, җанландыру) эзләп табу<br>В.Нуриев "Кем катырак суга?" Р.Вәлиева "Яңгыр белән кояш". | 1 | | |
| 31. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.** Әсәр исеменең төп мәгънә, эчтәлек белән туры килүе.<br>Г.Сабитов "Тәүге шатлык". | 1 | | |
| 32. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.** Дөрес тавыш төсмерләре белән уку өстендә эшләү.<br>Н.Гыйматдинова "Болын патшасы". | 1 | | |
| 33. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.** Геройларның характерына чагыштырма анализ.<br>А.Әхмәтгалиева "Безнең чишмә". Ф.Әминов."Су буе" картинасы. | 1 | | |
| 34. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.** Тиз һәм йөгерек уку күнекмәсен үстерү. | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Г.Бәширов. “Беренче кар”. | | | |
| 35. | **Әдәби әсәрләр. Шигърият.** Тавыш төсмерләре бирү күнекмәләрен булдыру.М.Мазунов “Яңа карлар ява, И.Солтан ”Кар ник шыгырдый?”, И.Солтан “Кар ник ява?”. | 1 | | |
| 36. | **Әдәби әсәрләр. Шигърият.** Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү. Р.Миңнуллин.”Кар бәйрәме”, Тылсымлы кыш”, С.Урайский.”Кыш шатлыгы”, “Туган ил”, Р.Вәлиева “Каникул вакытында”. | 1 | | |
| 37. | **Халык авыз иҗаты. Мәсәлләр.**<br>**Хикмәтле тормыш тәҗрибәсе туплыйбыз. 7 сәг**<br>Мәсәлләр турында гомуми төшенчә бирү. Мәсәлләрнең ике өлеше ( хикәяләү, мораль). Эзоп.”Давыл белән Кояш”, Г.Тукай. “Җил илә кояш”, Ф.Яруллин”Мактану бәласы”. | 1 | | |
| 38. | **Халык авыз иҗаты. Мәсәлләр.**<br>Мәсәлләрнең килеп чыгышы, үсеше. Г.Тукай “Көзге белән Маймыл”, Г.Шамуков “Көзге белән Маймыл”. | 1 | | |
| 39. | **Халык авыз иҗаты. Мәсәлләр.**<br>Мәсәлләрнең хайваннар турындагы әкиятләрдән килеп чыгуы Мәсәлләрнең мораль өлешенең мәкале. Т.Яхин.”Карга белән Төлке”,Т.Яхин.”Сыр бәласы”,Г.Шамуков.”Карга беләнТөлке”, Ф.Яруллин”Хәйләкәр куян”. | 1 | | |
| 40. | **Халык авыз иҗаты. Мәсәлләр.**<br>Мәсәлләрнең төп асылын, эчтәлеген аңлау. В.Радлов”Карганың хәйләсе”.Л.Толстой “Зирәк чәүкә” К.Насыйри.”Комсыз эт”. | 1 | | |
| 41. | **Мәсәлләр.**Татар язучыларының мәсәлләре.<br>Ә.Исхак.”Карт имән белән яшь егет”. М.Гафури”Ике чебен”, М. Саттар ”Кырмыска белән тирес корты”. | 1 | | |
| 42. | **Мәсәлләр.**Татар язучыларының мәсәлләре.<br>Г.Тукай “Төлке һәм йөзем җимеше”, Ә.Исхак ”Төлке һәм виноград”, К.Насыйри “Төлке белән әтәч”. | 1 | | |
| 43. | **Мәсәлләр.** Мәсәлләрнең тәрбияви роле.<br>М.Гафури ”Кәҗә белән төлке”, Г.Тукай.”Яшь агач”, “Бөкре агач”, Р.Вәлиева “Заман әкияте”. Г.Тукай “Аккош ,чуртан һәм кыскыч”<br>И.Крылов “Аккош,чуртан һәм кысла” | 1 | | |
| 44. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.**<br>**Көлке серләрен эзлибез. 5сәг.**<br>Авторның геройга мөнәсәбәтен ачыклау.<br>Ш.Галиев”Иншаның файдасы”, “Сүзләре белән үзләре”. В.Нуриев”Инша”. | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 45. | **Әдәби әсәрләр. Шигърият.**<br>Авторның геройга мөнәсәбәтен ачыклау. Шигырьне сәнгатьле итеп уку.<br>Р.Вәлиева “Көчле укучы” , “Каникул вакытында”. К.Тәңрекулиев “Эшчән” Гельды. | 1 | | |
| 46. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.**<br>Юмористик характердагы әсәрләрне кычкырып укыганда эмоциональ характерын чагылдыру. И.Юзеев.”Хатасыз ничек язарга?”.Р.Миңнуллин “Хаталар өстендә эшләү”. Л.Лерон “Инша”. | 1 | | |
| 47. | **Әдәби әсәрләр. Шигърият.**<br>Чагыштыру, контраст кебек гади әдәби алымнарны таба белү Р.Фәйзуллин ”Ничек яхшы булырга?”. Йолдыз “Ике җаваплы табышмак”. | 1 | | |
| 48. | **Әдәби әсәрләр. Шигърият.**<br>Шигырь һәм мәсәлләрнең охшашлыгы һәм аермасы .<br>Г.Морат”Тиргиләр”.З.Туфайлова”Трай”, Р.Вәлиев”Минеке,Р.Вәлиева”Сыер эзләгәндә”. | 1 | | |
| 49. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.**<br>**Герой ничек туа? 9сәг.**<br>Автор әсәрләрендә һәм халык экиятләрендәге сюжет кулланылышы<br>Ф.Яруллин”Тылсымлы ачкыч”, Р.Мингалим”Уйларга кирәк”. | 1 | | |
| 50. | **Әдәби әсәрләр. Шигърият.**<br>. Ф.Яруллин “Тылсымлы ачкыч”, Б.Рәхмәт “Ничек өйрәнергә”. | 1 | | |
| 51. | **Әдәби әсәрләр. Шигърият.**<br>Ф.Яруллин “Тылсымлы ачкыч”, Р.Вәлиева “Кышкы ямь”. Ф.Суюров ”Тукай музее картинасы”. | 1 | | |
| 52. | **Әдәби әсәрләр. Шигърият.**<br>.Ф.Яруллин “Тылсымлы ачкыч”, Йолдыз. “Белгәнен белми”, “Этем югалды бүген”. | 1 | | |
| 53. | **Әдәби әсәрләр. Шигърият.**<br>Шигырьне  сәнгатьле итеп укый һәм сөйли белү.М.Мирза ”Язның тәүге көннәре”, М.Г. “Ике каз белән бака”. | 1 | | |
| 54. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя** Г.Хәсәнов “Май”, Ә.Рәшит.”Яшенле яңгыр”, Г.Гыйлманов “Көзге урман” | 1 | | |
| 55. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.**<br>Әдәби әсәрләрнең башка сәнгать әсәрләре белән бәйләнеше. Г.Хәсәнов. “Май”.Ф.Садриев. “Белемле әби”. | 1 | | |
| 56. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.** Үз фикереңне әйтә белү. Г.Хәсәнов. “Май”, В.Гаршин “Ил гизүче бака”. | 1 | | |
| 57. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.** Г.Хәсәнов. “Май”, Н.Гыйматдинова “Дару” | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Х.Халиков “Витаминлы аш” | | | |
| 58. | **Әдәби әсәрләр. Шигърият.**<br>**Үткәннәр белән хәзергене чагыштырабыз. 14 сәг**<br>Шигырьне сәнгатьле итеп уку . Р.Фәйзуллин.”Онытма син!” М.Мирза “Идел-йорт” | 1 | | |
| 59. | **Әдәби әсәрләр. Шигърият.**<br>Рифма төшенчәсен аңлау. Л.Шагыйрьҗан.”Сөембикә манарасы”,В.Нуриев “Хуҗалар тавы”, Л.Леррон “Иртә уянасы килмәсә”. | 1 | | |
| 60. | **Әдәби әсәрләр. Шигърият.**<br>Лирик геройның  эчке дөнья-сын шигъри формада ачып бирү.<br>М.Мирза. “Без бабайсыз үстек”. М.Әлимбаев “Салават күпере”. | 1 | | |
| 61. | **Әдәби әсәрләр. Шигърият.**<br>Төрле язучыларның сугыш турында китаплары<br>Г.Гыйльманов “Нәсел агачы”, Л.Лерон “Сүз тыңлыйсың килмәсә”. | 1 | | |
| 62. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.**<br>Шигырьне аңлап һәм сәнгатьле итеп уку.<br>Ф.Кәрим.”Ант”, “Ватаным өчен” Г.Гыйльманов“Дәү әтинең әтисе”. | 1 | | |
| 63. | **Әдәби әсәрләр. Шигърият.**<br>Авторның иҗат алымнары, тормышы турында күзаллау.М.Җәлил “Кичер, илем!”. Х.Халиков “Рәхмәт сезгә, ветераннар!” | 1 | | |
| 64. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.**<br>Укылган әсәргә анализ ясау. В.Нуруллин “Бүреләр, үгез һәм без”. С.Рәхмәтуллин “Сандыктагы хәзинә” Р.Мәннән “Без музейга барабыз”. | 1 | | |
| 65. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.**<br>Геройның эчке дөньясын аның әйләнә-тирә дөньяны танып белүе аша күрсәтү.<br>Г.Ахунов.”Канатлар кая илтә ?”, А.Алиш “Ут йомырка”. | 1 | | |
| 66. | **Әдәби әсәрләр. Шигърият.**<br>Шагыйрьнең матурлыкны тоя белергә өйрәтүе.И.Юзеев.”Матурлыкны гына алып кит”, Г.Х. “Гөблә”. М.Җәлил-балалар өчен. | 1 | | |
| 67. | **Әдәби әсәрләр. Хикәя.**<br>Әдәби әсәрләрнең башка сәнгать әсәрләре белән бәйләнеше. Г.Бәширов.”Безнең Татарстан”.Р.Фәйзуллин”Нефть”, “Безнең КамАЗ”, Х.Туфан “Казан”. | 1 | | |
| 68. | **Әдәби әсәрләр. Шигърият.**<br>Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү.<br>Йолдыз.”Спортчы Шүрәле”.Г.Гыйльманов “Универсиада”,<br>Р.Миңнуллин “Кунакка килегез”, В.Хайруллина “Хозурлык һәм горурлык”.<br>Р.Миңнуллин шигырьләре Л.Шагыйрьҗан шигырьләре. | 1 | | |

**Әдәби уку предметы буенча бәяләү нормалары һәм критерийлары**

**Укуны бәяләү:**

**“5”**- текстны тулаем аңлап, авазларны һәм сүзләрне дөрес әйтеп, басымны дөрес куеп, сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп тиешле тизлектә укыганда, яттан өйрәнелгән шигырьне яхшы белү һәм сәнгатьле сөйләү, укуган текстка исем кую,сорауларга төгәл җавап бирә белү;

**“4”-** текстның эчтәлеген аңлап, сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп, әмма 2-3 орфографик хата җибәреп(авазларның әйтелешен бозу, басымны дөрес куймау, синтагмаларга бүленештә ялгышу) укыганда, шигырьне яттан белү, сәнгатьле сөйләү, кирәксез кабатлау, сүзләрнең урыннарын алыштыру;

**“3”-** текстның эчтәлеген өлешчә аңлап, 4-6 тупас орфографик хата җибәреп укыганда һәм уку тизлеге акрын булганда, эзлекле итеп сөйләмәү, текстны кисәкләргә бүлү һәмисем куч алмау,сөйләм хаталарын укытучы ярдәме белән генә төзтү;

**“2”-** текстның эчтәлеген бөтенләй аңламыйча, орфоэпик кагыйдәләрне бозып, 7дән артык әйтелеш хатасы җибәреп һәм уку тизлегенә куелган таләпләрне сакламыйча укыганда, укыганның эчтәлеген үзгәртеп сөйләү, өстәмә сораулар булса да, тестны кисәкләргә бүлә алмау.

**Диалогик сөйләмне бәяләү:**

Бирелгән ситуация буенча яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес, эчтәлеге ягыннан эзлекле һәм тулы диалогик сөйләм төзегәндә, “5”ле куела.

Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әмма репликаларның әйтелешендә һәм аерым сүзләрнең грамматик формаларында 2-3 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлекле диалогик сөйләм төзегәндә, “4”ле куела

Өстәмә сораулар ярдәмендә генә әңгәмә кора алганда, репликаларның әйтелешендә һәм сүзләрнең грамматик формаларында 4-6 хата җибәреп, эчтәлеген бозып диалогик сөйләм төзегәндә, “3”ле куела.

Бирелгән ситуация яки тема буенча диалог төзи алмаганда, “2”ле куела.

**Монологик сөйләмне бәяләү:**

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча әйтелеше, грамматик төзелеше ягыннан дөрес һәм эчтәлеге ягыннан тулы, эзлекле монологик сөйләм өчен “5”ле куела.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелгән, әмма аерым сүзләрнең әйтелешендә, грамматик формаларында яки җөмлә төзелешендә 2-3 хатасы булган монологик сөйләм өчен “4”ле куела.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелмәгән, сүзләрнең әйтелешендә, җөмлә төзелешендә 4-7 хатасы булган монологик сөйләм өчен “3”ле куела.

Өйрәнелгән темага яки бирелгән темага монолог төзи алмаганда, “2”ле куела.